**Республика Татарстан**
**Руководитель Исполнительного комитета Аксаринского сельского поселения Заинского муниципального района**

Ул. Ленина, д.42А с. Аксарино,
Заинский район, 423501

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлегенең башкарма комитеты җитәкчесе**

Ленин урамы, 42А нче йорт, Аксар авылы, Зәй районы, 423501

Телефон, факс 3-73-42. Электронный адрес: Aks.zai@tatar.ru, сайт:
http://zainsk.tatarstan.ru/rus/aksarinskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 13 30.07.2019

**«Сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында»**

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең 2019 нчы елның 10 нчы июлендәге 67/516 номерлы «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм җиһазлау турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү хакында» карары, Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге сайлау участоклары территориясендә махсус урыннар бүлеп бирергә һәм җиһазландырырга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен урыннар исемлеген расларга (Кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны Зәй муниципаль районы сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә Аксар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Ю.И.Гильманов**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Аксар авыл җирлеге Башкарма
комитет карарына
Кушымта
30.07.2019 № 13

**Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең сайлау участоклары территориясендә урыннар исемлеге**

| № п/п | Сайлау участогы № | Объектның исеме һәм урнашу адресы |
|---|---|---|
| 1. | 1453 | Мәгълүмат стенды<br>Аксар авылы, Мәктәп урамы |
| 2. | 1454 | Мәгълүмат стенды<br>Иске Тәкмәк авылы, Комсомольская урамы |
| 3. | 1455 | Мәгълүмат стенды<br>Икенче Бөгелде авылы, Пушкин урамы |